**Дүртенче чакырылыш**
**Татарстан Республикасы Азнакай район Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 33 - 6 «24» февраль 2021 ел

2020 елда Азнакай муниципаль районының социаль-икътисадый үсеше йомгаклары һәм 2021 елга бурычлар турында

«Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгының 2020 елгы социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2021 елга бурычлар турында хисабын тыңлап фикер алышканнан соң, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35, 36 статьялары, «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай район Советы карар итте**:**

1. «Азнакай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башлыгының 2020 елгы социаль-икътисадый үсеш йомгаклары һәм 2021 елга бурычлар турында хисабын игътибарга алырга (кушымта итеп бирелә).

2. Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетына, тиешле министрлыклар белән берлектә, дәгъва кылуны йөкләргә:

- Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы белән берлектә 7 җирлекнең генераль планнарын эшләү өчен, 28 җирлекнең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен финанслау чыганакларын билгеләү буенча тәкъдимнәр әзерләргә;

- Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белән берлектә эшкуарлык эшчәнлеге алып бару өчен кызыклы шартлар булдыру эшен оештырырга;

- бизнес вәкилләрен дәүләт ярдәме программаларына актив җәлеп итәргә;

- «Татнефть - Актив» ҖЧҖнең буш биналарына инвесторлар җәлеп итү буенча тәкъдимнәр әзерләргә;

- Азнакай муниципаль районына инвесторлар җәлеп итү буенча тәкъдимнәр әзерләргә;

- яңа резидентлар җәлеп итү өчен төзелгән сәнәгать мәйданчыкларының булган потенциалыннан файдалануны аерым контрольгә алырга, районда кече һәм урта бизнес алып бару өчен кызыклы шартлар формалаштыру эшен көчәйтергә;

- шәһәр чикләрен киңәйтү буенча документлар рәсмиләштерүне оператив рәвештә төгәлләргә һәм күпбалалы гаиләләргә максатчан билгеләнеше буенча җир кишәрлекләре тапшырырга;

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белән берлектә «Азнакай» Агропаркы төзелешен агропарклар төзүнең региональ программасына кертү турындагы мәсьәләне хәл итәргә;

- Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының һәм «Росагролизинг» АҖнең программаларын тыгыз файдаланып, районның авыл хуҗалыгы формированиеләренең техник паркын, шул исәптән КУЭ буенча да яңарту эшен көчәйтергә; техник паркны ел саен 30 %ка яңарту.

- барлык милек рәвешләрендәге хезмәткәрләрнең хезмәт хакын АПКга уртача республика әһәмиятенә җиткерергә;

- үсемлекчелек һәм терлекчелек продукциясен ел саен 3 %ка үстерүне тәэмин итәргә.

- 2025 елга барлык авыл хуҗалыгы оешмаларында цифрлы технологияләрне кулланып җитештерүгә күчүне тәэмин итәргә.

Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән берлектә ярлылык дәрәҗәсенең күрсәткечләрен киметү чараларын планлаштырырга;

- хезмәт өчен түләүне МРОТтан түбәнрәк киметкән предприятиеләр белән индивидуаль эшләр башкарырга;

ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә математика һәм рус теле буенча БДИ өчен балларның кимүе сәбәпләрен анализларга һәм бетерергә;

- эшче һөнәрләренең абруен күтәрү өчен район территориясендә кирәкле һөнәрләр буенча өлкән сыйныф укучылары арасында һөнәри юнәлеш алып бару;

«Азнакай политехника техникумы» дәүләт аграр һөнәри белем бирү учреждениесен тәмамлаучыларны 100 процент эшкә урнаштыру;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгы, Татарстан Республикасы тарифлар буенча Дәүләт комитеты белән берлектә Азнакай шәһәренең җылылык челтәрләрен һәм ГВС линияләрен төзү һәм алмаштыру эшләрен финанслау өчен инвестиция өлешен тарифына кертү мәсьәләсен хәл итәргә;

2021 елга балалар сәламәтләндерү лагерьларын капиталь ремонтлау программасына "Ак Чишмә" инвалидларын тернәкләндерү үзәге" бинасын ремонтлау һәм аның базасында балаларны савыктыру лагерен ачу өчен максатчан эш алып барырга;

2021 елга спорт корылмаларын капиталь ремонтлау республика программасына «Барс» спорт мәктәбен һәм ату-стенд комплексын кертүне тәэмин итәргә;

«Азнакай муниципаль районының Мәгариф идарәсе» МКУнә, «Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» МКУнә, Азнакай шәһәренең «Халыклар дуслыгы йорты» МКУнә:

милли рухи мирас нигезендә яшь буынга мәхәббәт һәм туган телгә хөрмәт тәрбияләү буенча максатчан эш алып барырга (Гыйләҗева З.С.), «Азнакай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы Хафизова Г.С, «Азнакай муниципаль районы мәдәният идарәсе» МКУ башлыгы)

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге  веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Рәис М.З.Шәйдуллин